| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 2016 ел, 20 май | | № 331 |

г. Казань

Татарстан Республикасы халкын гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә әзерләүне оештыру турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы һәм «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны укытуны оештыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2000 ел, 2 ноябрь, 841 нче, «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү турында» 2003 ел, 4 сентябрь, 547 нче карарлары нигезендә, хәрби низаглар вакытында һәм мондый низаглар нәтиҗәсендә барлыкка килгән куркынычлардан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халыкны саклану ысулларына әзерләүнең нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне эшләргә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 2 ноябрь, 841 нче карары белән расланган Гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны укытуны оештыру турында нигезләмә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2003 ел, 4 сентябрь, 547 нче карары белән расланган Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү турында нигезләмә нигезендә гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләүне планлаштырырга һәм гамәлгә ашырырга;

төп гомуми белем бирү программалары (мәктәпкәчә белемнең белем бирү программаларыннан тыш), урта һөнәри белемнең белем бирү программалары һәм югары белемнең белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеген тормышка ашыра торган оешмаларда һәм гражданнар оборонасы өлкәсендә һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә өстәмә һөнәри программалар буенча мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган башка оешмаларда, шул исәптән «Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-методика үзәге» белгечләрнең квалификациясен күтәрү максатларында өстәмә һөнәри белемнең Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәгариф учреждениесендә, муниципаль берәмлекләрнең гражданнар оборонасы буенча курсларында, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларда, эшләү, уку һәм яшәү урыны буенча тиешле төркемнәргә бүлеп, гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләүне тәэмин итәргә;

вазыйфаи затларны, гражданнар оборонасы белгечләрен һәм Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасын (алга таба – ГТХТС) әзерләүне оештырганда әзерлекнең дистанцион һәм күчмә методларын кертергә.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләүдә методик җитәкчелекне гамәлгә ашырырга;

ел саен «Чираттагы уку елына Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-методика үзәгенә тыңлаучылар туплау планын раслау турында» боерык проектын Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы җитәкчесенә раслауга кертергә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән берлектә ел саен «Иминлек мәктәбе» гомуми белем бирү оешмалары укучыларының республика һәм район ярышларын оештырырга һәм үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына муниципаль берәмлекләрнең гражданнар оборонасы буенча курсларын, гражданнар оборонасы буенча укыту-консультация пунктларын төзергә һәм укыту матди-техник база белән җиһазларга һәм аларның тиешле категориядәге вазыйфаи затлар һәм ГТХТС муниципаль звено белгечләрен һәм эшләмәүче халыкны әзерләү буенча эшчәнлеген оештырырга.

5. «Бөтенроссия дәүләт телевизион һәм радио тапшырулары компаниясе» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы «Татарстан» дәүләт телевизион һәм радио тапшырулары компаниясенә, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген

характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкның барлык категорияләрен әзерләү һәм бу өлкәдә белемнәрне пропагандалау өчен массакүләм мәгълүмат чараларын файдаланырга, ә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына һәм оешмаларга тәкъдим итәргә.

6. Түбәндәгеләрне үз көчен югалаткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы өлкәсендә Татарстан Республикасы халкын укытуны оештыру турында» 2001 ел, 17 август, 551 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү турында» 2003 ел, 31 декабрь, 693 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2006 ел, 14 август, 409 нчы карарының 4 пункты.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков